**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2022 елның 10 августы.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелде, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге башлыгының 2022 елның 27 июнендәге 52-РС номерлы карары белән билгеләнде.

Хәерби авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2022 елның 27 июнендәге 52-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1.2022 елның 4 июлендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;

2.2022 елның 29 июнендәге Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;

3.2022 елның 4 июлендәге Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 8 июлендәге 4453/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

2022 елның 8 июлендәге 4453/исх номерлы Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1.2022 елның 11 июлендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегенең рәсми сайтында;

2.2022 елның 8 июлендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);

3.2022 елның 11 июлендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4.Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү буенча Комиссия.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Прокофьева Любовь Ивановна - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе секретаре.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2022 елның«09»февралендәге Хәерби авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 25 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Халык тыңлауларын үткән дип таныргa;
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең Генераль планы проектын, 2022 елның«09»августындагы ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә гамәлдәге законнар нигезендә әлеге бәяләмәдән Өземтә бирүне гамәлгә ашырырга

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре _________________________ Прокофьева Л.И.